**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**Сарман авыл жирлеге**
**423350 Сарман авылы, Ленин ур.,52**
**тел.: 2-43-67, 2-45-38**
**E - mail: sar.sar@tatar.ru**
ИНН/КПП 1636005461/163601001

**Сармановское сельское поселение**
**САРМАНОВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
**423350 с. Сарманово, ул.Ленина, 52**
**тел.: 2-43-67, 2-45-38**
**E – mail: sar.sar@tatar.ru**
ИНН/КПП 1636005461/163601001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20 апреля 2016 г. № 5

Сарман авыл җирлеге торак пунктларының чикләрендә 2016 елның язгы-җәйге чорында объектларны янгынга каршы саклауны көчәйтү турында

Халыкны һәм территорияләрне янгынга каршы саклауны тәэмин итү, кешеләрнең һәлак булуына, янгыннарга һәм матди зыянга юл куймау, авыл хуҗалыгы һәм торак сектор объектларының янгын куркынычсызлыгын алга таба ныгыту максатларында, 2003 елның 6 октябрендәге Федераль закон нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ номерлы федераль закон, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясы, 2008 елның 22 июнендәге Федераль закон, № 123-ФЗ “Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында Техник регламент”, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы оешмаларында һәм торак пунктларында янгын куркынычсызлыгы чараларын ирекле янгын саклау көчләре белән гамәлгә ашыруның гомуми принциплары турында” 2004 елның 11 октябрендәге 448 номерлы карары һәм Сарман муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең 2016 елның 15 мартындагы 118 номерлы Карарын үтәү йөзеннән "янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында Техник регламент", "Татарстан Республикасы оешмаларында һәм торак пунктларында янгын куркынычсызлыгы чараларын гамәлгә ашыруның гомуми принциплары турында" 2016 елның язгы-җәйге чорында Сарман муниципаль районы объектларын һәм торак пунктларын янгынга каршы саклауны көчәйтү турында

карар бирәм:

1. 2016 елның язгы-җәйге чорында янгыннарны профилактикалауга һәм кисәтүгә юнәлдерелгән оештыру-техник чаралар комплексын гамәлгә ашыру.

2. Язгы – җәйге янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен үтәү, янгын белән бәйле гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда янгынга каршы гамәлләр кылу, беренчел янгын сүндерү чараларын тәэмин итү мәсьәләләре буенча халык белән аңлату эшләре алып баруны оештырырга.

3. Массакүләм мәгълүмат чаралары, җыелышлар, гражданнар җыеннары аша янгын куркынычсызлыгы мәсьәләләрен даими яктыртуны оештырырга.

4. Мич җылытуын, электр җылыту приборларын һәм җылылык генерацияләүче җайланмаларны эксплуатацияләгәндә белешмәлекләр әзерләү һәм тарату.

5. Янгын куркынычсызлыгы чараларын үтәү мәсьәләләре һәм кирәкле гамәлләр, янгын чыккан очракта күрсәтмә агитация урнаштыруны оештырырга.

6. Имин булмаган гаиләләр, шулай ук өлкән яшьтәге кешеләргә янгын куркынычсызлыгы турында аңлату эшләре алып бару максатыннан, Башкарма комитет хезмәткәрләре белән берлектә имин булмаган гаиләләр, шулай ук өлкән яшьтәге кешеләр һәм амораль яшәү рәвеше алып баручы затлар яшәү урыннарын тикшерүне оештырырга.

7. Халыкка, оешма һәм учреждение җитәкчеләренә җиткерү:

- биналарга һәм су чыганакларына керү юлларын һәм подъездларны янгын һәм оператив техниканы узарга комачаулаучы киртә җайланмаларыннан азат итү турында мәгълүмат;

-язгы чорда оешмалар, учреждениеләр һәм шәхси торак секторы территорияләрен чүп-чардан һәм коры үләннән арындыру.

8. Торак пунктларда ирекле янгын формированиеләре эшен көчәйтергә.

9. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында", PRAVO.TATARSTAN.RU( Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

10. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Сарман муниципаль районы
Сарман авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе И.Я.Хасанов